ЯҢАЛЫКЛАР

# Дәүләт гаепләве журналист Искәндәр Сиражины 400 мең сум штрафка тартуны сорады

әле генә



Искәндәр Сиражи

**Мәхкәмә утырышы иртәгә дәвам итәчәк.**

23 июньдә Вахитов район мәхкәмәсендә журналист **Искәндәр Сиражига** ачылган җинаять эшенә бәйле чираттагы мәхкәмә утырышы дәвам итте. Бу хакта "Сиражи бәян итә" дип исемләнгән Telegram-каналында аның хатыны **Эльмира Сиражи** хәбәр итә.

"Прокурор Сиражи абзагызга 400 мең, Барлевага (адвокат Инна Барлева – ред.) 500 мең штраф сорады...", дип язды ул.

Элегрәк Сиражи гаепләү документы 207 биттән тора дип белдергән иде.

2024 елның 9 октябрьдә куәт оешмасы вәкилләре Сиражи өендә һәм редакциядә тентү уздырды. Журналистның үзен Тикшерү комитетына алып киттеләр һәм аннан соң изоляторга яптылар.

Шул ук көнне Сиражи ачлык игълан итүен белдерде. Аның хатыны төшергән видеода ул "мондый маддә нигезендә болай утыртмыйлар, мин вакыты чикләнмәгән ачлык игълан итәм", дип белдерде.

Сиражи шәхси тормыш турында мәгълүмат җыю һәм аны тарату турындагы (Җинаять кодексының 137нче маддәсе 1нче өлеше) җинаять эшендә шикләнелде. Ул моны Ибраһим Зәкиев исемле кешегә ачылган җинаять эшендәге (соңрак Татарстан Югары мәхкәмәсе присяжныйлары аны азат иткән) ике шаһиткә каршы эшләгән дип фаразлана. Зәкиев үзе исә Сиражи шикләнелгән эштә шаһит булып бара.

"Реальное время" элек язуынча, Искәндәр Сиражиның YouTube-каналында чыккан 55 минутлык видеомөрәҗәгатендә ике кешенең шәхси мәгълүматлары күренгән. Бу видеода сүз Ибраһим Зәкиев эше турында бара. Имеш, видеода Зәкиевны үтерүдә гаепләгән ике кешенең — Сабиров һәм Сафиуллинның фотолары һәм видеолары күренгән. Бу ике кеше, Сиражи шәхси мәгълүматларыбызны чыгарды дип, тикшерү комитетына шикаять иткән.

Журналистка карата тентү беренче тапкыр гына узмый. 2023 елның 16 ноябрь иртәсендә аның өенә куәт оешмасыннан тентү белән килделәр. Килү сәбәбен Азатлык Радиосы журналисты Алсу Кормаш эшенә бәйле дип аңлатып, рәсми кәгазь күрсәткәннәр. Аның, хатыны Эльмира Сиражиның бөтен телефоннары, компьютерлары алынды. Тентү "Сиражи сүзе" редакциясе урнашкан офиста да булды. Аннан да бөтен техника алынды. Берничә көннән соң тентү көнендә Эльмира Сиражи "Мәдәни җомга" редакциясенә килә алмавы аркасында аңлатма язуны таләп иттеләр. Соңрак ул гариза язып эштән китте.

🛑 **Русиядә Азатлык сайты томаланды, нишләргә?Безнең кулланма.**
🌐 **Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар сакланган